**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**
**Тутай авыл җирлеге башлыгы**

# КАРАРЫ

2020 ел, 17 февраль №1

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлегенең,җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау турында**

“Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 11 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә **карар итәм:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлегенең,җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализ үткәрү тәртибен расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Апас муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Тутай авыл җирлеге башлыгы Н. М. Насретдинова**

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Тутай авыл җирлеге
башлыгының
2020 елның 17 февралендәге
1 номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлегенең,җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе**

1.Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлегенең,җирле үзидарә органнарына (алга таба - җирле үзидарә органнарына) гражданнар мөрәҗәгатьләрен (алга таба - мөрәҗәгатьләрне) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2.Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләренә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында гамәлгә ашырыла.

3.Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау Тутай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе), гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау өчен җаваплы (алга таба - вазыйфаи зат) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү вакыты-елга бер тапкыр: ел үткәннән соң билгеләнә.

5.Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тиешле чорга кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен исәпкә алып, шул исәптән язма рәвештә, электрон хәбәрләр рәвешендә, шулай ук Интернет-кабул итү, гражданнарны шәхси кабул итү барышында һәм телефон аша кабул ителә.

6.Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча, хисап чорыннан соң килүче айның 10 коненә кадәр вазифаи зат аналитик белешмә төзи.

7.Аналитик белешмә үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

- кергән, адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләр саны турында;
- гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында;
- шәхси кабул ителгән гражданнар саны турында;
- гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында;
- мөрәҗәгатьләр тематикасы турында;
- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат (булганда).

8.Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең аналитик белешмәсе, шулай ук билгесез затлар мәнфәгатьләренә кагылышлы иң актуаль мәсьәләләр буенча аңлатмалар "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Апас муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырыла.